ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МАМАДЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.М.Джалиля, д.23/33, г. Мамадыш,
Республика Татарстан, 422190

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫНЫҢ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ
М.Җәлил ур, 23/33 й., Мамадыш ш.,
Татарстан Республикасы, 422190

Тел.: (85563) 3-15-00, 3-31-00, факс 3-22-21, e-mail: mamadysh.ikrayona@tatar.ru, www.mamadysh.tatarstan.ru

**Постановление** **Карар**

№ 253 от «14» 03 2018 г.

Суд тарафыннан юридик хокуксыз
яки чикләнгән юридик хокуклы дип
танылган затларга карата опека һәм
попечительлек билгеләү буенча дәүләт
хезмәте күрсәтүнең административ
регламентын раслау турында

“Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында” 27 июль, 2010 ел, № 210 - ФЗ Федераль законны гамәлгә ашыру максатыннан, “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына опека һәм попечительлек өлкәсендә Татарстан Республикасының аерым дәүләт вәкаләтләрен бирү турында” 20 март, 2008 ел, № 7 ТРЗ Татарстан Республикасы законы, Татарстан республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында” 17.04.2015 ел, № 259 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының карары, Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгының 26.02.2016 ел, 358 нче санлы боерыгы, “Опека һәм попечительлек турында” 24 апрель, 2008 ел, № 48- ФЗ Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 17.11.2010 ел, 927 нче санлы карары, “Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 17.11.2010 ел, 927 нче санлы карарына үзгәрешләр кертү турында” 19.11.2016 ел, 1221 нче санлы карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты

к а р а р б и р ә:

1. Суд тарафыннан юридик хокуксыз яки чикләнгән юридик хокуклы дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентны яңа редакциядә расларга (Кушымта).

2. “ Мамадыш муниципаль районы башкарма комитетының суд тарафыннан юридик хокуксыз яки чикләнгән юридик хокуклы дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында” 24.06.2016 ел, 738 нче санлы карарның 1 пункт, 1.2. подпунктны гамәлдән чыккан дип танырга.

3. Суд тарафыннан юридик хокуксыз яки чикләнгән юридик хокуклы дип танылган затларга карата опека һәм попечительлек билгеләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентны раслау турындагы карарны интернет мәгълүмати - коммуникацион челтәрендәге Татарстан Республикасының хокукый

рәсми порталында һәм Мамадыш муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары В.И.Никитинга йөкләргә.

Җитәкче И.М. Дәрҗеманов